ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

11.12.2019 Казан шәһәре № 3-3/э

«Туполев» гавами акционерлык җәмгыяте филиалы – С.П.Горбунов исемендәге Казан авиация заводы һәм «Челтәр компаниясе» ачык акционерлык җәмгыяте челтәр оешмалары арасында үзара исәп-хисаплар ясау өчен электр энергиясе тапшыру хезмәте күрсәтүгә 2020-2024 елларга аерым тарифлар билгеләү хакында

«Электр энергетикасы турында» 2003 елның 26 мартындагы 35-ФЗ номерлы федераль законга, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Электр энергетикасында җайга салынулы бәяләр (тарифлар) өлкәсендә бәя хасил итү турында» 2011 елның 29 декабрендәге 1178 номерлы карарына, Федераль тарифлар хезмәтенең "Ваклап сату (кулланучылар) базарында электр (җылылык) энергиясенә җайга салынулы тарифлар һәм бәяләр хисаплау буенча методик күрсәтмәләр раслау турында» 2004 елның 6 августындагы 20-э/2 номерлы һәм «Электр энергиясен тапшыру хезмәтләренә зарури тулай табышны озак вакытлы индексацияләү методын кулланып билгеләнә торган тарифларны хисаплау буенча методик күрсәтмәләр раслау турында» 2012 елның 17 февралендәге 98-э номерлы боерыкларына, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты турында нигезләмәгә туры китереп, Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. «Туполев» гавами акционерлык җәмгыяте филиалы – С.П.Горбунов исемендәге Казан авиация заводы һәм «Челтәр компаниясе» ачык акционерлык җәмгыяте челтәр оешмалары арасында үзара исәп-хисаплар ясау өчен электр энергиясен тапшыру хезмәте күрсәтүгә, шушы карарның 1 нче кушымтасына туры китереп, 2020 елның 1 гыйнварыннан 2024 елның 31 декабренә кадәр 2020-2024 елларга календарь буенча бүленгән аерым тарифлар билгеләргә.

2. Үзенә карата электр энергиясе тапшыру хезмәтләренә тарифлар территориаль челтәр оешмасы эшчәнлеген дәвамлы җайга салу параметрлары нигезендә билгеләнә торган «Туполев» гавами акционерлык җәмгыяте филиалы –

С.П.Горбунов исемендәге Казан авиация заводы өчен, шушы карарның 2 нче кушымтасына туры китереп, 2020-2024 елларга озак сроклы җайга салу параметрлары билгеләргә.

3. Әлеге карарның 3 нче кушымтасы нигезендә 2020-2024 елларга «Туполев» гавами акционерлык җәмгыяте филиалы – С.П.Горбунов исемендәге Казан авиация заводының кирәкле тулай керемен (югалтуларга түләүне исәпкә алмыйча) билгеләргә.

4. Бу карар рәсми басылып чыккан көненнән башлап 10 көн узгач үз көченә керә.

Рәис вазыйфаларын башкаручы Л.П.Борисова

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 11.12.2019 № 3-3/э карарына 1 нче кушымта

Татарстан Республикасы территориясендә «Туполев» гавами акционерлык җәмгыяте филиалы – С.П.Горбунов исемендәге Казан авиация заводы һәм «Челтәр компаниясе» ачык акционерлык җәмгыяте челтәр оешмалары арасында үзара исәп-хисаплар ясау өчен электр энергиясен тапшыру хезмәте күрсәтүгә 2020 елның 1 гыйнварыннан 2024 елның 31 декабренә кадәр календарь буенча бүленгән аерым тарифлар

| т/с | Челтәр оешмасының аталышы | Ел | 1 гыйнвардан 30 июньгә кадәр | | | 1 июльдән 31 декабрьгә кадәр | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | Ике ставкалы тариф | | Бер ставкалы тариф | Ике ставкалы тариф | | Бер ставкалы тариф |
| | | | Электр челтәрләрен карап тоту ставкасы | Технологик чыгым (югалту) өчен түләү ставкасы | | Электр челтәрләрен карап тоту ставкасы | Технологик чыгым (югалту) өчен түләү ставкасы | |
| | | | сум/МВт·ай | сум/МВт·сәг | сум/кВт·сәг | сум/МВт·ай | сум/МВт·сәг | сум/кВт·сәг |
| 1 | «Туполев» гавами акционерлык җәмгыяте филиалы – С.П.Горбунов исемендәге Казан авиация заводы – «Челтәр компаниясе» ачык акционерлык җәмгыяте | 2020 | 103 018,69 | 0 | 0,22477 | 103 018,69 | 0 | 0,22477 |
| | | 2021 | 123 766,89 | 0 | 0,27004 | 123 766,89 | 0 | 0,27004 |
| | | 2022 | 126 626,75 | 0 | 0,27628 | 126 626,75 | 0 | 0,27628 |
| | | 2023 | 129 572,41 | 0 | 0,28271 | 129 572,41 | 0 | 0,28271 |
| | | 2024 | 132 606,44 | 0 | 0,28933 | 132 606,44 | 0 | 0,28933 |

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының тариф чишелешләрен кабул итүне оештыру, контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 11.12.2019 № 3-3/э карарына 2 нче кушымта

Үзенә карата электр энергиясе тапшыру хезмәтләренә тарифлар территориаль челтәр оешмасы эшчәнлеген дәвамлы җайга салу параметрлары нигезендә билгеләнә торган «Туполев» гавами акционерлык җәмгыяте филиалы – С.П.Горбунов исемендәге Казан авиация заводы өчен 2020-2024 елларга озак сроклы җайга салу параметрлары

| т/с | Татарстан Республикасында челтәр оешмасының аталышы | Ел | Контрольдәге чыгымнарның база дәрәҗәсе | Контрольдә тотыларга тиешле чыгымнарның нәтиҗәлелек индексы | Активлар саны буенча контрольдәге чыгымнарның сыгылмалылык коэффициенты | Электр челтәрләре аша тапшырганда электр энергиясен югалту дәрәҗәсе | Электр энергиясен тапшыру ноктасына тапшыруны туктатуның уртача дәвамлылыгы күрсәткече | Электр энергиясен тапшыру ноктасына тапшыруны туктатуның уртача ешлыгы күрсәткече | Күрсәтелә торган хезмәтләрнең сыйфат дәрәҗәсе күрсәткече |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | млн сум | % | % | % | сәгать | данә | |
| 1 | «Туполев» гавами акционерлык җәмгыяте филиалы – С.П.Горбунов исемендәге Казан авиация заводы – «Челтәр компаниясе» ачык акционерлык җәмгыяте | 2020 | 8 667,0 | 3 | 75 | 0 | 0,013 | 1,5 | 1 |
| | | 2021 | X | 3 | 75 | X | 0,013 | 1,5 | 1 |
| | | 2022 | X | 3 | 75 | X | 0,013 | 1,5 | 1 |
| | | 2023 | X | 3 | 75 | X | 0,013 | 1,5 | 1 |
| | | 2024 | X | 3 | 75 | X | 0,013 | 1,5 | 1 |

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының тариф чишелешләрен кабул итүне оештыру, контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 11.12.2019 № 3-3/э карарына 3 нче кушымта

«Туполев» гавами акционерлык җәмгыяте филиалы – С.П.Горбунов исемендәге Казан авиация заводының 2020-2024 елларга кирәкле тулай кереме (югалтуларга түләүне исәпкә алмыйча)

| т/с | Татарстан Республикасында челтәр оешмасының аталышы | Ел | Югалтулар өчен түләүне исәпкә алмыйча, челтәр оешмасының ЗТТ |
|---|---|---|---|
| | | | мең сум |
| 1. | «Туполев» гавами акционерлык җәмгыяте филиалы – С.П.Горбунов исемендәге Казан авиация заводы | 2020 | 12 598,36 |
| | | 2021 | 15 135,70 |
| | | 2022 | 15 485,44 |
| | | 2023 | 15 845,67 |
| | | 2024 | 16 216,71 |

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының тариф чишелешләрен кабул итүне оештыру, контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге